ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛАН-БӘКСӘР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛАН-БЕКСЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19

тел./факс 8(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** — **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**26 апрель 2021 г.** — **№ 12**

# Алан-Бәксәр авыл җирлегендәге чүп-чар, кипкән үлән, яфракларны һәм территориядәге башка калдыклар, материаллар һәм эшләнмәләрне яндыру урыннарын һәм алымнарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары нигезендә, Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы торучанлыкны арттыру максатларында Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**:

1. Торак пунктларның гомуми кулланылыштагы җирләрендә, шулай ук торак пунктлар территорияләрендә урнашкан шәхси йортлар территорияләрендә учак ягу, махсус билгеләнгән һәм моның өчен җиһазландырылган урыннардан тыш, ашарга пешерү өчен ачык ут куллану, шулай ук әлеге карарның 2 һәм 3 пунктларында билгеләнгән урыннардан тыш, чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыкларны, материалларны яки эшләнмәләрне яндыру тыела.

2. Чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яки эшләнмәләрне яндыру урыны итеп билгеләргә:

| № п/п | Торак пунктның исеме | Чүп-чар яндыру урыны | Кем җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Алан-Бәксәр авылы | торак пункттан төньяк-көнбатыштарак | Башкарма комитет |
| 2. | Алатский спиртзавод авылы | торак пункттан төньяк-көнбатыштарак | Башкарма комитет |
| 3. | Гәр авылы | торак пунктның көньяк-көнчыгыш өлешендә | Башкарма комитет |
| 4. | Шөмлән авылы | торак пунктның көньяк-көнчыгыш өлешендә | Башкарма комитет |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5. | Әсән авылы | торак пунктның көньяк-көнчыгыш өлешендә | Башкарма комитет |

3. Чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яки эшләнмәләрне яндыру ысулы итеп - ачык учак формасын билгеләргә.

4. Ачык учакны куллану урыны:

- якындагы объекттан (биналар, корылмалар, ачык склад, печән-салам эскертләре) кимендә 50 метр, Парк зонасыннан 100 метр ераклыкта яки аерым үсүче ылыслы һәм яфраклы агачлардан һәм яшь агачлардан яисә агач төркемнәреннән 100 метр ераклыкта урнашырга тиеш.;

- ачык ут куллану урыны тирәсендәге территория 10 метр радиуста коры-сары агачлардан, коры үләннән, бура калдыкларыннан, башка янучан материаллардан чистартылырга һәм 2 метрдан ким булмаган киңлектәге янгынга каршы, минеральләштерелгән полоса белән бүленергә тиеш.;

- ачык ут кулланучы зат янгын сүндерү өчен җиһаз белән тәэмин ителергә тиеш: чиләк, көрәк, сулы мичкә, ком тутырылган яшнек, янгынны локальләштерү һәм бетерү өчен, шулай ук янгын сүндерү бүлекчәсен чакыру өчен мобиль элемтә чарасы.

5. Чүп-чар, үләннәр, яфраклар, агач әйберләр һәм башка калдыклар, материаллар яки эшләнмәләр яндыру, җил тизлеге секундына 5 метрдан артмаган очракта гына рөхсәт ителә.

6. Әлеге карар Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим кертелгән чорда үз көчен югалтмый.

7. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Алан-Бәксәр авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе З.Р.Гарифуллина

Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы
Совет Алан-Бексерского сельского поселения
ИНН 1616000659